**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре,Совет мәйданы, 27**

**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Муниципальное образование город Арск**
**Арского муниципального района**
**Совет города Арск**
**422000, г. Арск, Площадь Советская , 27**

**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Арча шәһәр Советы**

**КАРАРЫ**

**“18” декабрь 2020 ел** **№20**

Арча шәһәр Советының 2018 елның 20 декабрендәге 114 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (21.03.2019 ел, №116, 19.11.2019 ел, №134, 05.03.2020 ел, №142, 14.08.2020 ел, № 150 үзгәрешләр белән)

2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Арча шәһәр Советының 2018 елның 20 декабрендәге 114 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (21.03.2019 ел, №116, 19.11.2019 ел, №134, 05.03.2020 ел, №142, 14.08.2020 ел, № 150 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 10.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәрнең урынбасары тиешле вазыйфа биләгән вакытта, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау максатыннан, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмый.";

2) 30 статьяның 30.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30.4. муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе — И.Г. Нуриев

Совет
города Арск